


# Көллият сулышы

**№2 25.11.2022**

***27 нче ноябрь – Халыкара әниләр көне – уңаеннан шигъри мизгелләр***

***3 бит***

***“Студент булу җиңелме?”***

сораугa жавап

***5 нче биттә***

***“Татар кызы – 2022”***

**турында тулырак**

***7 бит***




27 нче октябрь көнне “Сәйдәш” мәдәният үзәгендә “Чиста булачак” исемендәге Яшьләр экологик хәрәкәте кысаларында еллык йомгак ясау буенча Республика фестивале булып узды. Көллиятебезнең активистлары – Самира Мөхәммәдова һәм Лилия Ниматова әлеге чарада оештыручы буларак катнаштылар.

10 нчы ноябрьдә Балтач муниципаль районында 2022 нче елның көзендә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле егетләр арасында хәрби-гамәли спорт төрләре буенча Спартакиаданың зональ этабы узды. Арча педагогия көллияте егетләре лаеклы чыгыш ясап, 1 нче урынны яуладылар.






16 нчы ноябрь көнне көллиятебездә "Студентлар баскетбол лигасы" кысаларында баскетбол буенча Республика ярышларының зональ этабы узды. Ир-ат һәм хатын-кыз командалары арасында 1 нче урыннарны “Арча педагогия көллияте" командалары яулады.

17 нче ноябрь көнне Федерация Советы рәисенең беренче урынбасары Андрей Турчак Нократ Аланыннан килгән яшүсмерләрне «Батырлык өчен» медаль белән бүләкләде. Алар арасында безнең 141 нче төркем студенты Филимонов Максим да бар иде.



***Редколлегия:***
***Рузилә Каюмова, Камилә Абдуллина, Зилә Фазлыева***

**_Бердәмлектә – көч!_**

# 4 ноябрь

## Халыклар бердәмлеге көне



















# *“Әни” диеп язып куйдым...*



### *Әнием...*

*Әнием-бәгырем, сине яратуым*
*Сүзләр белән ничек аңлатыйм?*
*Күңелемдәге изге хисләремне*
*Саклап кына торам, таратмыйм.*

*Чын күңелдән изге теләкләрем,*
*Синең өчен генә, әнием.*
*Үстергәнсең мине иманлы итеп,*
*Рәхмәләрем чиксез, кадерлем!*

*“Балам” диеп әйткән сүзләрең,*
*Бигрәк нурлы, әнием, күзләрең.*
*Күз карашың җанны эретә,*
*Нурлы кояш синең йөзеңдә.*

*Иң  беренче аяк баскан чакта*
*Кулларыңа тотынып  атладым.*
*Минем бәхетем өчен чын күңелдән*
*Кайгыртуың тоеп, шатландым.*

*Кайгы-хәсрәт килсә, беләм, әнием*
*Иңнәреңә ятып елыйсым.*
*Мәңге шулай тоеп яшәр идем*
*Кулларыңның, әнием, җылысын,*
*Йөрәгеңнең, әнием, җылысын...*

***<u>Самирә Таҗитова, 111 нче төркем</u>***

### *Единственной маме на свете.*

*Спасибо, мама, я тебя благодарю за всё,*
*что ты сделала,*
*Столько труда надо мной тобою было проделано.*
*Жизнь моя была обрисована акварелями*
*Цветными, среди доставленной мной канителями.*

*Сегодня день прохладный, но тёплый от мысли,*
*Слова добрыми нитями над тобою повисли.*
*И слов «Спасибо» в этот день не счесть.*
*И не думай, что это просто жалкая лесть.*

*Тобою труд был проделан неимоверный,*
*План воспитания шёл закономерный,*
*И в итоге получилась я –*
*Человек, то есть твоё дитя.*

*Я тебя очень сильно люблю,*
*И сей словами я укреплю*
*Этот день, очень нужный и важный,*
*И лёгкий, как самолётик бумажный.*

*Пусть всё будет у тебя хорошо,*
*И всегда дышится путь свежо,*
*С мыслями доброго, яркого цвета,*
*Как песнь на старой, советской кассете.*

*Здоровья, удачи и ярких надежд,*
*И долгую жизнь без разных невежд.*
*Я тебе всегда своё подставлю плечо,*
*И всё будет у нас хорошо…*

***<u>Ангелина Беспятых, 111 группа</u>***

# Мин – студент!

## Мәңге онытылмас...



***27 нче октябрь көнне Арча педагогия көллиятендә барлык студентлар да зарыгып көтеп алган Беренче курс студенты көне узды. Бәйрәмдәге кызыклы мизгелләргә әйдәгез бергәләп күз салыйк әле!***

*Студентларны матур күңел ачу программасы көтеп алды. Директорыбыз Гөлнара Фидаил кызы исә беренче курсларны студент тормышына аяк басулары белән тәбрик итте, һәркемгә дә уңышлар һәм бәйрәм рухы теләде.*



*Бәйрәмебезне җырчы Илгәрәй тагын да бизәп җибәрде. Ул тамашачыларны үзенең матур, дәртле җырлары белән таң калдырды. Кайчандыр үзе дә Арча педагогия көллиятен тәмамлаган кеше буларак, студент вакытындагы кызыклы вакыйгаларны исенә төшереп, барыбызны көлдерергә дә өлгерде әле танылган җырчы.*

*Бәйрәмнең төп сәбәпчеләре – беренче курс студенлары – искиткеч номерлар күрсәттеләр. Һәрбер группа үзе әзерләгән үзенчәлекле видео һәм кызыклы чыгышы белән сәхнәне дер селкетте дисәң дә артык булмас. Матур җырлар, дәртле биюләр, хәтта акробатик номерлар... Әлбәттә боларны сүз белән генә җиткереп бетереп булмый, үз күзләрең белән күрергә кирәктер.*



*Ничек кенә булмасын, әлеге бәйрәм безнең өчен чын мәгънәсендә онытылмаслык бер вакыйга булды! Ул көнне яңгыраган теләкләр һәм киңәшләр киләчәк студент тормышыбызда да безнең өчен якты маяк булып торыр дип ышанам...*

***Зилә Фазлыева, 112 нче төркем.***

# *Студент булу җиңелме?*

**Камилә Ганиева (112 нче төркем студенты):**
**“Бу көллиятне бетерсәң, син белемле булачаксың”.**

***“Студент” дигәч тә, күз алдына тәвәккәл, кыю, максатчан һәм, әлбәттә инде, заманча киенгән яшь кеше килеп баса. Ләкин нәкъ менә шундый студент булу өчен нишләргә кирәк соң? Ә яңа гына укырга кергәннәргә студент тормышына ничек ияләшергә? Моның өчен уку йортларында тиешле шартлар тудырылганмы? Гомумән, студент булу җиңелме соң? Без бу хакта күптән түгел генә студент тормышына аяк баскан студентларның үзләреннән сорарга булдык. Таныш булыгыз, бүгенге әңгәмәбезнең герое – 1 нче курста белем алучы Камилә исемле мөлаем кыз. Аның уй-кичерешләре белән бергәләп танышып үтик.***



**Камилә, ни өчен син нәкъ менә Арча педагогия көллиятен сайларга булдың?**

Бу уку йортын сайларга миңа күбрәк гаиләм тәэсир итте. “Син монда керсәң, күбрәк белем ала аласың, тәҗрибә туплый аласың. Бу көллиятне бетерсәң, бик яхшы булыр иде”,- дип мине өндәделәр. Әлбәттә инде, эти-әниләрнең киңәшләреннән соң үземнең дә шушы көллияткә укырга керү теләге, ниндидер бер омтылыш барлыкка килде. Баштагы вакытларда мин кайсы бүлеккә керәсемне яхшылап уйлап бетермәгән идем әле. Аннан соң инде үземнең теләгем белән башлангыч сыйныфлар укытучысы булырга карар кылдым.

**Уку дәверендә нинди авырлыклар белән очрашырга туры килде? Уку белән бәйле өметләрең акландымы?**

Башта бик курыккан идем. Авыррак булыр, мине читкә этәрерләр дигән уйлар да булды. Мәктәптә бөтен кешегә дә ияләшкән идем, монда әле беркемне дә белмим, шуңа дуслар да таба алмам дип уйладым. Ләкин хәзер инде төркемебездә дә үзара бик яхшы аралашабыз. Хәтта әле уку буенча мәктәптән җайлырак дип әйтсәң дә була. Бәлки беренче курста булган өчен генә шулай тоеладыр.

**Нинди дәресләр сиңа күбрәк ошый, җиңел бирелә?**

Җәмгыять белеме дәресе миңа бик ошый. Безне ул фәннән Энҗе Даниловна укыта. Шулай ук ОБЖ дан да Марат Альфредович бик яхшы аңлата. Татар әдәбиятын да (укытучысы – Гөлия Хәйдәровна) бик яратып укыйм. Әлегә дәресләр авыр түгел. Әмма, әле укырга да укырга...

**Укудан тыш нәрсәләр белән кызыксынасың? Уку йортында үзеңнең теләгән өлкәңдә үсәргә барлык мөмкинлекләр дә тудырылганмы?**

Әйе, минемчә, көллияттә студентлар өчен бөтен тиешле шартлар да бар. Нинди өлкәдә генә булмасын, барысын да яхшы аңлаталар. Мин әле тагын “Экскурсовод”ка да йөрим. Ул безнең “Әлифба музеенда” уза. Без анда музейдагы истәлекле әйберләр белән танышабыз, үзебез дә әкренләп алар турында сөйләргә өйрәнәбез. Сөйләм телен үстерү өчен дә бу менә дигән мөмкинлек. Монда алган белемнәребезне без шулай ук киләчәктә

дә куллана алабыз. Бүген әле шулай ук “Әлифба музеенда” конкурс та булачак, мин анда катнашам. Икенче курстан башлап инде инглиз теле буенча китмәкче булам. Инглиз телен ныклап өйрәнеп, киләчәктә балаларны өйрәтергә, инглиз теле укытучысы булырга хыялланам.

Шулай ук  “Стрельба” – “Ату” буенча түгәрәккә дә йөрим. Минем инде күптәннән үземне әлеге юнәлештә сынап карау теләге бар иде. Әле мәктәптә укыганда ук ОБЖ дәресләрендә ату белән шөгыльләнгәнем булды. Ләкин көллияттә яхшырак аңлаталар, барысын да тиешенчә күрсәтәләр. Миңа бик ошый. 6 декабрь көнне ярыш та булырга тиеш, шунда катнашырга исәп бар. Шунысы кызык, “Стрельба” буенча түгәрәккә күбрәк кызлар йөри. Монда бик игътибарлы, төгәл булу мөһим, чөнки бер генә ялгыш хәрәкәтең була икән, пулялар читкә китәчәк.

**Көллияттә үзеңә яңа дуслар таба алдыңмы? Төркемдәшләрегез арасында бердәмлек бармы?**

Әйе, бердәмлек бар. Барлык төркемдәшләрем белән дә уртак тел таба алдым. Һәрберсе белән дә кызыксынуларыбыз туры килә. Тәнәфесләр бик кызык үтә безнең: җыр тыңлап, биеп, бер-беребез белән сөйләшеп! Барыбыз да әйбәт укырга тырышабыз. Төркемебездә барлыгы 26 кеше, бер кыз дистанцион рәвештә белем ала. Менә әле күптән түгел генә аның туган көне булып узды. Без барыбыз бергә махсус аны котлар өчен Биектауга барып кайттык.

**“Беренче курс студенты” көне дә үтеп китте. Хәзер инде үзеңне чын студент итеп тоясыңмы?**

Башта беренче ике айда бик аңлап бетереп булмады, ияләшмәгән дә идек. Соңрак, әлеге бәйрәм үткәч, сәхнәдә чыгыш ясагач, барыбер дә үзеңне инде икенче төрле тоясың икән. Без үзебез биедек кызлар белән. Ике атна буена чыгышыбызны әзерләдек. Әлеге чара безне тагын да бердәмлеккә этәрде.




**Ничек уйлыйсың, студент булуы җиңелме?**

Әлегә җиңел дип уйлыйм. Мин үзем Балтач районы Пүскән авылыннан. Монда килеп, икенче, өченче курслар белән танышканда күпләре арасында: “Авыр инде, нигә монда килдең?”- дип әйтүчеләр дә булды хәтта. Ләкин мин башкача уйлыйм, һәм барысы да яхшы булыр дип ышанып калам. Көллияттәге укытучыларның дәрес алып бару, аңлатулары миңа бик ошый. Хәтта мәктәптә аңламаган кайбер әйберләрне дә мин монда килгәч кенә аңладым.

Үземнең дус кызым белән тулай торакта бер бүлмәдә торабыз. Хәзер инде әкрен генә тулай торак тормышына да ияләштек. Кичләребез бик күңелле үтә. Кызлар белән бик яхшы аралашабыз.

Иң зур теләгем – әйбәт кенә укып чыгу. Бабаем әйтмешли: “Бу көллиятне бетерсәң, син белемле булачаксың”. Үзебезнең туганнар арасында да монда укып чыгучылар бар. Инглиз телен әйбәтләп өйрәнсәм, башлангыч сыйныфлар укытучысы белемен алсам, үземнең төп максатыма ирешеп, тормышымның беренче баскычын үткән кебек булыр идем.

***Рузилә Каюмова.***

# Татар кызы – 2022

## *Илсөя Зәкәрова:*
## *“Мин җиңәрмен дип уйламадым да”.*



***15 нче ноябрь көнне Арча педагогия көллиятендә Татарстан Республикасының урта һөнәри белем бирүче уку йортлары студентлары арасында Республикакүләм “Татар кызы - 2022” бәйгесе үткәрелде. Бәйгенең 1 нче (сайлап алу) турында 28 уку йортыннан килгән студент кыз көч сынашты. Көллиятебезнең 3 курс студенты Илсөя Зәкәрова 1 нче урынга лаек булды. Илсөяне мәртәбәле бәйгедә җиңүе белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Ә кокурсның мөһим этаплары һәм әлеге җиңүгә ирешү өчен нинди сынаулар аша үтәргә туры килгәне турында чын татар кызы – Илсөя безгә үзе сөйләп бирде.***

**Ни өчен син "Татар кызы" бәйгесендә катнашырга булдың? Әзерләнү этаплары ничек үтте?**

Мин узган елны «Татар кызы» бәйгесен алып барган идем. Бу елны миңа укытучылар катнашырга тәкъдим иттеләр, һәм мин ризалаштым. Әзерләнү этаплары, әлбәттә, бик авыр булды. Ләкин мин бар көчемне туплап, тырыштым һәм чыгыш ясадым.

**Бәйгедә катнашучыларны ничек тасвирлый аласың, алар белән көч сынашуы авыр булдымы?**

Бәйгедә катнашучы кызлар барысы да сөйкемле, эшчән, уңган иде. Алар белән көч сынашу миңа ошады. Чын мәгънәсендә, алар бик яхшы, лаеклы конкурентлар булдылар.

**Бәйге барышындагы сынаулар арасында синең өчен иң авырын һәм иң җиңел бирелгәнен әйтеп үтә аласыңмы?**

Иң авыры минем өчен үзеңнең бөтен булган талантларыңны күрсәтү бәйгесе булгандыр, чөнки миңа әлеге этапта сөйләргә дә, җырларга да, фортепианода уйнарга да туры килде. Ә иң җиңеле минем өчен “Кул эше” булды, чөнки кул эше белән шөгыльләнгәндә тынычланасың һәм үзеңнең барлык сәләтләреңне күрсәтәсең.

**Алдан ук үзеңә "җиңәргә" дигән максат куйдыңмы яисә төп теләгең катнашу гына идеме?**

Минем төп теләгем катнашып карау һәм үземне сынау иде. Шуңа күрә, мин җиңәрмен дип уйламадым да.

**Ничек уйлыйсың, чын татар кызы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**


Чын татар кызы тәмле итеп ашарга пешерә белергә, кул эшенә оста булырга тиеш һәм, әлбәттә инде аның сөйләм теленең дә бай булуы мөһим.

**Әңгәмәдәш – Камилә Абдуллина, 112 нче төркем**


# *Кызык-мызык*


Минем өчен имтихан – ул һәрвакыт бәйрәм!


Укудан кайткач
Завершение работы...


Көн дә, җәйме, кышмы, яңгырмы, кармы, кирәкме, кирәкмиме, иртә белән будильник:


Давайте я вам переведу
тысяча триста сорок рублей шестьдесят копеек
Давай
мең өч йөз кырык сум алтмыш тиен, не благодарите
Пятерочкада бер случай...


За окном тагын сугробыыыыы
Снеговик давно көтәәәәә


Хәзер балаларны киендерәләр
Безне ничек киендерәләр иде